| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 ноябрь 2013 Казан ш. 3-6/э №лы

***Татарстан Республикасы халкы өчен электр энергиясенә карата бәяләргә (тарифларга) төшерелгән каэффицентларны куллануы турында***

«Электр энергетика турында» 26 март 2003 35-ФЗ №лы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикада көйләүле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя билгеләнүе турында» 29 декабрь 2011 1178№лы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты БОЕРА:

1. Шәһәр торак пунктларында аш пешерерлек стационар электр плитәләр һәм (яки) электр җылыткычлар белән кирәкле рәвештә җиһазландырылган өйләрдә яшәүче халык өчен электр энергиясенә карата бәяләргә (тарифларга) 0,7 төшерелгән каэффицентын билгеләргә.

2. Авыл торак пунктларында яшәүче халык өчен электр энергиясенә карата бәяләргә (тарифларга) 0,7 төшерелгән каэффицентын билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның 1 нче һәм 2 нче пунктларында күрсәтелгән төшерелгән каэффицентлар 01 январь 2014 елыннан башлап 31 декабрь 2014 елына хәтле гамәлдә була.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә нәшер ителү көненнән ун көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р. Зарипов